**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 18 май № 290

г. Казань

Махсуслаштырылган оешмаларның Татарстан Республикасында инновацион территориаль кластерларны үстерүгә бәйле чыгымнарын финанслар белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 31 октябрь, 823 нче карары белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасының «2015 – 2018 елларга Кама инновацион территориаль-җитештерү кластерын үстерү» ярдәмче программасы чараларын тормышка ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Махсуслаштырылган оешмаларның Татарстан Республикасында инновацион территориаль кластерларны үстерүгә бәйле чыгымнарын финанслар белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибен (карарга теркәлә) расларга.

2. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына 30 көн эчендә субсидия бирүгә заявка һәм субсидиядән файдалану турында хисап формаларын расларга.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

F:\KARAR\2017\290.docx

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 18 май, 290 нчы карары белән расланды

Махсуслаштырылган оешмаларның Татарстан Республикасында инновацион территориаль кластерларны үстерүгә бәйле чыгымнарын финанслар белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибе

1. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә эшләнде һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 31 октябрь, 823 нче карары белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасының «2015 – 2018 елларга Кама инновацион территориаль-җитештерү кластерын үстерү» ярдәмче программасын тормышка ашыру кысаларында махсуслаштырылган оешмаларның Татарстан Республикасында инновацион территориаль кластерларны үстерүгә бәйле чыгымнарын финанслар белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр (алга таба – субсидияләр) бирү механизмын билгели.

Әлеге Тәртип максатларында махсуслаштырылган оешма буларак аны гамәлгә куючыларның берсе Татарстан Республикасы һәм (яки) гамәлгә куючысы бары тик Татарстан Республикасы булган оешма булган, устав нигезендә Татарстан Республикасында инновацион территориаль кластерны (алга таба – кластер) үстерүне методик, оештыру, эксперт-аналитик һәм мәгълүмати яктан тәэмин итүне гамәлгә ашыра торган коммерциячел булмаган оешма аңлашыла.

2. Субсидияләр тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына (алга таба – бюджет акчасы белән баш эш итүче) бу Тәртипнең 1 нче пунктында күрсәтелгән максатларга расланган бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

3. Субсидияләр кластерда катнашучы кимендә 60 оешма эшчәнлеген алар белән төзелгән шартнамәләр нигезендә яраштыруны гамәлгә ашыра торган махсуслаштырылган оешмаларга бирелә.

4. Субсидияләр субсидия бирү турында килешү (алга таба – килешү) төзү планлаштырыла торган айга кадәр килгән айның беренче числосына түбәндәге таләпләргә туры килгән махсуслаштырылган оешмаларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләреннән тыш) бирелә:

махсуслаштырылган оешма үзенең эшчәнлеген Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашыра;

махсуслаштырылган оешманың Россия Федерациясе законнары нигезендә үтәү вакыты җиткән Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычы булмаска тиеш;

махсуслаштырылган оешманың Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетына субсидияләр, бюджет инвестицияләре (шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән) кайтару буенча вакыты чыккан бурычы һәм Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетына башка вакыты чыккан бурычы булмаска тиеш;

махсуслаштырылган оешма үзгәртеп оештыру, ябылу, банкротлык процессында тормаска тиеш һәм аның хуҗалык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга чикләүләре булмаска тиеш;

махсуслаштырылган оешма теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы раслый торган салым салуның ташламалы салым режимы бирә торган һәм (яки) мондый юридик затларга карата финанс операцияләре үткәргәндә мәгълүмат ачу һәм бирү күздә тотылмаган дәүләтләр һәм территорияләр (офшор зоналар) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган устав (җыелма) капиталларындагы чит ил юридик затлары катнашу өлеше барысы бергә 50 процентттан арткан чит ил юридик заты, шулай ук Россия юридик заты булмаска тиеш;

махсуслаштырылган оешма башка норматив хокукый актлар, муниципаль хокукый актлар нигезендә әлеге Тәртипнең 1 нче пунктында күрсәтелгән максатларга Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетыннан акча алучы булмаска тиеш.

5. Субсидия аларны финанслар белән тәэмин итү чыганагы булган чыгымнарның юнәлешләре булып түбәндәгеләр тора:

а) махсуслаштырылган оешма хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү һәм матди яктан бүләкләүгә чыгымнар;

б) элемтәне тәэмин итүгә чыгымнар;

в) офис җиһазлары, электрон-хисаплау техникасы (мәгълүмат эшкәртү өчен башка җиһазлар), программа белән тәэмин итү, периферия җайланмалары, күчермә алу-күбәйтү җайланмасы, лаборатория җиһазлары сатып алуга чыгымнар;

г) коммуналь хезмәтләр һәм биналар арендасы өчен түләүгә чыгымнар;

д) башка агымдагы чыгымнарга (командировка, канцтоварлар сатып алу, чыгым материаллары һәм башка чыгымнар) акча;

е) чит оешмаларның түбәндәгеләргә юнәлдерелгән хезмәтләре өчен түләүгә чыгымнар:

кластерда катнашучы ике һәм аннан күбрәк оешма тарафыннан бергә башкарыла торган кластерны үстерү проектларын эшләү һәм гамәлгә ашыруда булышлык күрсәтү;

кластерда катнашучы оешмалар мәнфәгатьләрендә кадрларны әзерләү, яңадан әзерләү, квалификацияләрен күтәрү һәм стажировкалауны, консультация хезмәтләре күрсәтүне оештыру;

кластерда катнашучы оешмаларга базарга яңа продуктлар (хезмәтләр) чыгаруда, кластерда катнашучы оешмаларның фәнни-техник өлкәдә кооперациясен, шул исәптән чит ил оешмалары белән, үстерүдә ярдәм күрсәтү;

кластерда катнашучы оешмалар мәнфәгатьләрендә булган өлкәдә күргәзмә-ярминкә чаралары һәм коммуникатив чаралар, шулай ук аларның чит илдә үткәрелә торган күргәзмә-ярминкә чараларында һәм коммуникатив чараларда катнашуын оештыру.

6. Субсидия алу өчен махсуслаштырылган оешмалар бюджет акчасы белән баш эш итүчегә түбәндәге документларны тапшыра:

бюджет акчасы белән баш эш итүче раслаган форма буенча субсидия бирүгә заявка;

гамәлгә кую документлары күчермәләре;

күләмен дәлилли торган мәгълүматны күрсәтеп, чыгымнарның планлаштырылган юнәлешләрен исәпләп чыгаруны үз эченә алган финанс-икътисадый нигезләмәне теркәп, әлеге Тәртипнең 5 нче пунктында күрсәтелгән юнәлешләр буенча махсуслаштырылган оешма җитәкчесе раслаган чыгымнар сметасы;

махсуслаштырылган оешманың әлеге Тәртипнең 3 нче пунктына туры килүен раслый торган документлар;

махсуслаштырылган оешманың бу Тәртипнең 4 нче пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында махсуслаштырылган оешманың җитәкчесе һәм баш бухгалтеры имзалаган белешмә (ирекле формада);

махсуслаштырылган оешманың Россия Федерациясе законнары нигезендә үтәү вакыты җиткән Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычы булмавын раслый торган салым органы белешмәсе;

махсуслаштырылган оешманың үзгәртеп оештыру, ябылу, банкротлык процессында тормавы һәм аның хуҗалык эшчәнлеген алып гамәлгә ашыруга чикләүләре булмавы турында махсуслаштырылган оешма җитәкчесе имзалаган гарантия хаты.

Документлар махсуслаштырылган оешма тарафыннан кәгазьдә һәм электрон мәгълүмат саклау җайланмасында тапшырыла.

7. Бюджет акчасы белән баш эш итүче:

субсидия бирүгә заявка кертелгән көнне аны терки;

теркәгән көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә кертелгән документларны карап тикшерә һәм субсидия бирү турында яки субсидия бирүдән баш тарту хакында карар кабул итә.

8. Субсидия бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

әлеге Тәртипнең 6 нчы пунктында күрсәтелгән документларны тапшырмау (тулы күләмдә тапшырмау);

тапшырылган документларның, аларда булган мәгълүматларның әлеге Тәртиптә каралган таләпләргә һәм шартларга туры килмәве;

махсуслаштырылган оешма биргән мәгълүматның дөрес булмавы.

Субсидия бирүдән баш тарткан очракта бюджет акчасы белән баш эш итүче

карар кабул иткән көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган ике көн эчендә махсуслаштырылган оешмага бу турыда хәбәрнамә җибәрә.

9. Субсидия бирү өчен нигез булып Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән бертип форма нигезендә бюджет акчасы белән баш эш итүче һәм махсуслаштырылган оешма арасында төзелә торган килешү тора.

10. Килешүдә субсидиянең күләме, максатчан билгеләнеше, субсидия аларны финанслар белән тәэмин итү чыганагы булган чыгымнарның юнәлешләре, субсидиядән файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткечләре мәгънәләре, субсидияне күчерү тәртибе, субсидиядән файдалану хакында һәм субсидиядән файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткечләренә ирешү турында хисаплылык тапшыру тәртибе, вакытлары һәм формалары, хисап финанс елында файдаланылмый калган субсидияне субсидия алучы тарафыннан агымдагы финанс елында кайтару очраклары, бюджет акчасы белән баш эш итүче Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән килешү буенча аларны файдалану ихтыяҗы булу турында карар кабул иткәндә, хисап финанс елында файдаланылмый калган субсидия аларны финанслар белән тәэмин итү чыганагы булган чыгымнарны гамәлгә ашыру мөмкинлеген күздә тоткан шарт, алынган акча исәбеннән чит ил валютасы алуны тыю турында нигезләмәләр, Россия Федерациясе валюта законнары нигезендә югары технологияле импорт җиһазлары, чимал һәм комплектлау җайланмалары сатып алганда (кайтартканда) гамәлгә ашырыла торган операциялардән, шулай ук әлеге акчаны бирү максатларына ирешүгә бәйле башка операцияләрдән тыш, алган акча исәбеннән чит ил валютасы алуны тыю турында нигезләмәләр, бюджет акчасы белән баш эш итүче һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан махсуслаштырылган оешманың субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен, махсуслаштырылган оешманың әлеге Тәртип һәм төзелә торган килешү шартларын үтәү турындагы нигезләмәне үтәүгә тикшерүләр гамәлгә ашыруга махсуслаштырылган оешманың ризалыгы күздә тотыла.

11. Субсидия күләмен исәпләү түбәндәге формула буенча гамәлгә ашырыла:

C = P1 + P2 + P3 +...+Pn,

монда:

C – субсидия күләме;

P1, P2, P3… Pn – әлеге Тәртипнең 5 нче пунктында күрсәтелгән юнәлешләр буенча бирелә торган субсидия исәбеннән чыгымнар.

12. Субсидия бирү турында карар кабул иткән көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә килешү проекты бюджет акчасы белән баш эш итүче тарафыннан махсуслаштырылган оешмага имзалау өчен җибәрелә.

13. Махсуслаштырылган оешма ягыннан имзаланган килешүне аннан алган көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә килешү бюджет акчасы белән баш эш итүче тарафыннан имзалана.

14. Бюджет акчасы белән баш эш итүче килешүгә ике як та кул куйган көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә субсидияне махсуслаштырылган оешманың Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсендә ачылган шәхси счетына күчерә.

15. Махсуслаштырылган оешма әлеге Тәртиптә һәм килешүдә билгеләнгән субсидия бирү шартларын бозган (бюджет акчасы белән баш эш итүче һәм дәүләт финанс контроле органнары үткәргән тикшерүләр фактлары буенча ачыкланган), субсидиядән файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткечләренә ирешмәгән очракта, субсидия Татарстан Республикасы бюджеты кеременә бюджет акчасы белән баш эш итүченең тиешле таләбен алган көннән соң 30 көн эчендә кайтарылырга тиеш.

16. Килешүдә каралган очракларда махсуслаштырылган оешма тарафыннан хисап финанс елында файдаланылмый калган субсидияләр Татарстан Республикасы бюджеты кеременә хисап елыннан соң киләсе торган елның 1 февраленнән дә соңга калмыйча кире кайтарылырга тиеш, бюджет акчасы белән баш эш итүче Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән килешү буенча әлеге акчадан файдалану ихтыяҗы булу турында карар кабул итү очракларыннан тыш.

17. Субсидияне, әлеге Тәртипнең 15 һәм 16 нчы пунктларында күрсәтелгән субсидиянең калган өлешен кайтару вакытларын бозган очракларда бюджет акчасы белән баш эш итүче субсидияне, субсидиянең калган өлешен кайтару вакыты чыккан көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә әлеге акчаны мәҗбүри тәртиптә кайтару буенча Россия Федерациясе законнары нигезендә чаралар күрә.

18. Бюджет акчасы белән баш эш итүче һәм дәүләт финанс контроле органнары әлеге Тәртиптә һәм килешүдә билгеләнгән субсидияне кайтару шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүгә тикшерү үткәрә.

19. Субсидиядән максатчан һәм нәтиҗәле файдалануны тикшерүдә тоту бюджет акчасы белән баш эш итүче тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

F:\KARAR\2017\290.docx